# ТАТАРСТАН
# ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
# ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ

*№ 8*
*август*
*2012*

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
РӘСМИ БАСМАСЫ
Казан
2012

ЯЗЫЛУ ИНДЕКСЫ  78696
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ:
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәсми басмасы

Формат 60x84 $^{1}/_{16}$. Тираж 150 экз.

© Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, 2012

Эчтәлек

# I
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАБУЛ ИТКӘН ЗАКОННАР ҺӘМ КАРАРЛАР

1148. «Вөждан ирекe турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ......................14

1149. «Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2012 елның 3 августындагы чираттан тыш утырышы көн тәртибе турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..................16

1150. «Татарстан Республикасында дини экстремистлыкны профилактикалауның һәм аңа каршы көрәшнең торышы һәм чаралары турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..................................17

1151. «Вөждан ирекe турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 7405-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..................................20

1152. «Вөждан ирекe турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (7405-4 номерлы проект)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .............................21

# II
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

1153. «Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының чираттан тыш утырышын чакыру турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* .......................................................22

1154. «Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2012 елның 3 августындагы чираттан тыш утырышы каравына кертелүче мәсьәләләр турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ..........................................................................22

1155. «Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2012 елның 3 августындагы чираттан тыш утырышын телевидение һәм радио аша турыдан-туры трансляцияләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ................23

## III

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЛАРЫ ҺӘМ БОЕРЫКЛАРЫ

1156. «Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ................................24

1157. «Татарстан Республикасының Атказанган транспорт хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* .............24

1158. «Татарстан Республикасының Әтнә районы Иске Өҗем авылы территориясендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга иминлексезлеге сәбәпле урнаштырылган карантинны бетерү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ......................25

1159. «Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ........................................................................26

1160. «Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ..........................................27

1161. «Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ..........................................27

1162. «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы структурасына үзгәреш кертү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ........28

1163. «Б.И. Исмәгыйлевны Татарстан Республикасы Президентының Эксперт идарәсе башлыгы итеп билгеләп

кую турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ...........................................................................30

1164. «Татарстан Республикасының Балтач районы Көек авылы территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга иминлексезлеге сәбәпле урнаштырылган карантинны бетерү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ..................................................30

1165. «Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасы Балтач районының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ........................31

1166. «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның акчалата бүләкләүләрен индексацияләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ........................................................32

1167. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ........33

1168. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник тәэмин итүне тормышка ашыручы хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ...............................................................35

1169. «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның акчалата бүләкләүләрен индексацияләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ........................................................36

1170. «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты структурасына һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ........................39

1171. «М.Я. Моратовны Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең беренче урынбасары

итеп билгеләп кую турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....................................................44
1172. «М.И. Гатинны Татарстан Республикасы Президентының Дини берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлек идарәсе башлыгы вазыйфасыннан азат итү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* .............44
1173. «Татарстан Республикасы Президентының аерым актларына үзгәрешләр кертү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ..................................44
1174. «Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ............47
1175. «Татарстан Республикасының Атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ..................................48
1176. «Татарстан Республикасының Атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ........................................48
1177. «Татарстан Республикасының Атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ........................................49
1178. «Татарстан Республикасының Атказанган физик культура хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* .........49
1179. «Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ......................50
1180. «Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ......................50
1181. «Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ......................51
1182. «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ..................................52

1183. «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ..................................53
1184. «Татарстан Республикасының Атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ................................53
1185. «Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* .............54
1186. «Татарстан Республикасының Атказанган физик культура хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ..............54
1187. «Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ................................55
1188. «Татарстан Республикасының Атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* .....................................55
1189. «Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* .................................56
1190. «Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ..................................56
1191. «Татарстан Республикасының Атказанган табибы» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* .......................................57
1192. «Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан» медале белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ......................57
1193. «Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* .......................58
1194. «Татарстан Республикасы Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ...........59

1195. «Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ..................59
1196. «Татарстан Республикасының Атказанган машина төзүчесе» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ..................60
1197. «Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ..................................60
1198. «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты структурасына һәм хезмәткәрләренең чик санына үзгәрешләр кертү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ...........................................61
1199. «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ................................63
1200. «Татарстан Республикасы Президентының «Созвездие-Йолдызлык» республика фестиваль хәрәкәтенә ярдәм итү буенча чаралар турында» Указына үзгәреш кертү хакында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ...........................................................65
1201. «Татарстан Республикасының Мөслим районы Тойгелде авылы территориясендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ......................69
1202. «Татарстан Республикасының Теләче районы Лесной поселогы территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга иминлексезлеге сәбәпле урнаштырылган карантинны бетерү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ................................70
1203. «Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ..71

1204. «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ..........72
1205. «Татарстан Республикасының Атказанган энергетигы» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ..........72
1206. «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ..........73
1207. «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының гомуми санын раслау турында» Указына үзгәреш кертү хакында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ..........74
1208. «Татарстан Республикасының Атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ..........75
1209. «Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ..........76
1210. «Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ..........76
1211. «Татарстан Республикасының Атказанган нефтьчесе» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ..........77
1212. «Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ..........77
1213. «Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ..........78
1214. «Әлмәт шәһәре төзелүенең 60 еллыгын һәм Татарстан Республикасында нефть ятмаларын эшкәртә башлауның 70 еллыгын бәйрәм итү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ..........78

1215. «Татарстан Республикасының Түбән Кама шәһәренең Студентлар урамы территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга иминлексезлеге сәбәпле урнаштырылган карантинны бетерү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ........................82

1216. «Татарстан Республикасының Тукай районы Сәет авылы территориясендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ................................................83

1217. «Татарстан Республикасының Атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ......................84

1218. «Татарстан Республикасының Атказанган нефтьчесе» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ..................................84

1219. «Татарстан Республикасының Атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ..................................85

1220. «Татарстан Республикасының Атказанган фән эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ........................86

1221. «Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ..................................86

1222. «Татарстан Республикасының Атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ........................................87

1223. «Татарстан Республикасының Атказанган торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ..............................................................87

1224. «Татарстан Республикасының Атказанган транспорт хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ..................88

1225. «Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* .....................88
1226. «Татарстан Республикасының Атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* .................................89
1227. «Татарстан Республикасының Атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ...................................89
1228. «Татарстан Республикасының Атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ...90
1229. «Татарстан Республикасының Атказанган ветеринария табибы» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* .........................90
1230. «Татарстан Республикасының Атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ..........................................91
1231. «Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* .......................91
1232. «Татарстан Республикасының Атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ......................................92
1233. «Татарстан Республикасының Атказанган физик культура хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ..92
1234. «Татарстан Республикасының Атказанган агрономы» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ..........................................93
1235. «Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* .....................94
1236. «Татарстан Республикасының Атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ......................................94

1237. «Татарстан Республикасының Атказанган терлекчесе» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* .....................95
1238. «Татарстан Республикасының Атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....95
1239. «Татарстан Республикасының Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* .....96
1240. «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары һөнәри белем бирү дәүләт мәгариф учреждениеләре көндезге уку бүлекләренең укучыларның бөтенроссия һәм халыкара олимпиадалары җиңүчеләреннән һәм бүләк алучыларыннан булган студентлары өчен Татарстан Республикасы Президенты стипендияләрен билгеләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* .............................................96
1241. «Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасының Атказанган җиртөзәре» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* .......................................................98
1242. «Татарстан Республикасының Атказанган геологы» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ............................................98
1243. «Татарстан Республикасының Атказанган транспортчысы» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* .......................99
1244. «Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ...............................99
1245. «Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ..................................100
1246. «Татарстан Республикасының Атказанган торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....................................................................................100

1247. «Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ................................101
1248. «Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* .......................101
1249. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........102
1250. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........102
1251. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........102
1252. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........103
1253. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........103
1254. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........104
1255. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........104
1256. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........104
1257. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........105
1258. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........105
1259. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........106
1260. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........106
1261. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........107
1262. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........107
1263. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........108
1264. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........108
1265. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........109
1266. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........109
1267. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........110
1268. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........110
1269. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........111
1270. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........111
1271. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........112
1272. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........112

# I
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАБУЛ ИТКӘН ЗАКОННАР ҺӘМ КАРАРЛАР

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 1148. «Вөждан ирекe турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 3 августында
кабул ителде

**1 статья**

Кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекен яклау, дини экстремизмны кисәтү, конфессия эчендәге һәм конфессияара татулыкны ныгытуга ярдәм итү максатларында «Вөждан ирекe турында һәм дини берләшмәләр турында» 1999 елның 14 июлендәге 2279 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 8 (II өлеш); 2001, № 12; 2004, № 2 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 3; 2011, № 6 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбулада:

а) түбәндәге эчтәлекле дүртенче абзац өстәргә:

«кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен яклау максатларында,»;

б) дүртенче – алтынчы абзацларны тиешенчә бишенче – җиденче абзацлар дип санарга;

2) 11 статьяда:

а) 1 пунктта «граждан» сүзен «Россия Федерациясе гражданы» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 пунктта «дини оешмаларның үз билгеләүләре» сүзләреннән соң «, әгәр мондый билгеләүләр законга каршы килмәсә,» сүзләрен өстәргә;

3) 15 статьяның 5 пунктында «мәгълүм үрнәктәге» сүзләрен «федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнгән үрнәктәге» сүзләренә алмаштырырга;

4) 17 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3, 4 пунктлар өстәргә:

«3. Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән дини оешмалар руханилар вазыйфаларына кандидатларга таләпләр, шул исәптән Россия Федерациясе территориясендә урнашкан, шулай ук чит илләр территориясендә урнашкан, дипломнары билгеләнгән тәртиптә танылган мәгариф учреждениеләрендә алынган дини белем булу, шулай ук руханилар вазыйфаларын биләүгә бәйле чикләүләр урнаштыралар.

Әлеге пунктта күрсәтелгән таләпләр дини оешманың вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә.

4. Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән дини оешмалар дини оешманың уставында күрсәтелгән дин тәгълиматының кануный бердәмлеген тәэмин итү тәртибен билгелиләр.»;

5) 19 статьяда:

а) 4 пунктта «медицина» сүзен «дәвалау-профилактика һәм хастаханә» сүзләренә алмаштырырга;

б) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Башка очракларда гавами гыйбадәт кылулар, башка дини йолалар һәм тантаналар митинглар, урам йөрешләре һәм демонстрацияләр үткәрү өчен билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

6) 27 статьяда:

а) 1 пунктта «төзергә хокуклы» сүзләрен «төзиләр» сүзенә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 5, 6 пунктлар өстәргә:

«5. Дини оешмаларда эшләүче гражданнар үз мәнфәгатьләрен яклау өчен һөнәр берлекләре төзергә, аларга керергә, һөнәр берлеге эшчәнлеге белән шөгыльләнергә һәм һөнәр берлегеннән чыгарга хокуклы.

6. Дини оешмаларда хезмәткә кагылышлы хокук мөнәсәбәтләре, дини берләшмәләр турында законнарда билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, хезмәт законнары белән җайга салына.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 4 августы
№ 64-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1149. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2012 елның 3 августындагы чираттан тыш утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2012 елның 3 августындагы чираттан тыш утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасында дини экстремистлыкны профилактикалауның һәм аңа каршы көрәшнең торышы һәм чаралары турында.

2. «Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 7405-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 3 августы
№ 2334-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 1150. Татарстан Республикасында дини экстремистлыкны профилактикалауның һәм аңа каршы көрәшнең торышы һәм чаралары турында

2012 елның 19 июлендә Казан шәһәрендә Татарстан Республикасы мөфтиенә һөҗүм итүгә һәм Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең уку-укыту бүлеге башлыгын үтерүгә бәйле вәзгыять турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты мәгълүматын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында катнашучыларның чыгышларын тыңлап фикер алышканнан соң, кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен, конституциячел корылыш нигезләрен яклау, иминлек тәэмин итү, Татарстан Республикасында үзара аңлашу һәм татулык атмосферасын ныгыту, Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче төрле конфессия һәм милләт вәкилләре арасында урнашкан толерантлык мөнәсәбәтләрен саклап калу максатларында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары Ә.Ә. Сәфәровның мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Конфессия эчендәге каршылыкларны хәл итүнең теләсә нинди көч куллану ысулларын, дини экстремистлык фактларын, Татарстанда төрле милләт һәм дин вәкилләренең тынычлыгына һәм күпгасырлык килешеп янәшә яшәүләренә янау омтылышларын гаепләргә.

3. Татарстан Республикасы мөселманнары өммәтенә, башка конфессияләр вәкилләренә, Татарстанда яшәүче гражданнарга республикада дини төсмердәге экстремистлык һәм түзеп тора алмаучанлык таралуга каршы көрәштә берләшергә чакырып мөрәҗәгать итәргә.

4. Татарстан Республикасы Президентына Татарстан Республикасында этникара мөнәсәбәтләрне килештерү мәсьәләләре буенча даими нигездә эшләүче ведомствоара эшче төркемне Татарстан Республикасында этникара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне килештерү мәсьәләләре советы итеп үзгәртү турындагы мәсьәләне карауны тәкъдим итәргә.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты:

1) 2012 – 2014 елларга Татарстан Республикасында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау буенча республика максатчан программасын гамәлгә ашыру барышы турындагы мәсьәләне карарга һәм 2012 елның 1 декабренә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тиешле мәгълүмат тапшырырга тиеш;

2) Татарстан Республикасы Дәүләт Советына түбәндәгеләрне әзерләп кертергә тиеш:

2012 елның 1 декабренә кадәр бу өлкәдә законлылыкны алга таба ныгыту һәм гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен тайпылышсыз тәэмин итү, дини экстремистлыкка илтүче фактларны тамырдан юкка чыгару максатында вөҗдан иреге һәм дини берләшмәләр турында федераль законнарны камилләштерүгә юнәлдерелгән федераль закон проектын;

2013 елның 1 апреленә кадәр рухи кыйммәтләрне тарату, милләтара һәм конфессияара тынычлыкны һәм татулыкны ныгыту, граждан җәмгыяте институтларының толерантлыкны пропагандалауда катнашуы, милләтара һәм конфессияара мәдәни багланышларны үстерү максатларында Татарстан Республикасы законнарын алга таба камилләштерү буенча тәкъдимнәрне.

6. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына муниципаль берәмлекләр вәкиллекле органнарының чираттагы утырышларында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау мәсьәләләрен карауны, шул исәптән дини өлкәдә, шулай ук җирле үзидарә органнарының  муниципаль берәмлек территориясендә гамәлдә булган дини һәм милли берләшмәләр вәкилләре белән үзара хезмәттәшлеге өчен җаваплы вазыйфаи затларны билгеләүне тәкъдим итәргә.

7. Татарстан Республикасында хокук саклау органнары, тиешле процессуаль эшләр башкарганда гражданнарның конституциячел хокукларын тайпылышсыз үтәүне тәэмин итеп, 2012 елның 19 июлендә Казан шәһәрендә Татарстан Республикасы мөфтиенә ясалган һөҗүмне һәм Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең уку-укыту бүлеге башлыгын үтерүне тизрәк ачу буенча кирәкле барлык чараларны күрергә тиеш.

8. Татарстан Республикасы прокуратурасына, Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

1) максатлары яисә гамәлләре экстремистлык юнәлешендә булган иҗтимагый һәм дини берләшмәләрне ачыклау һәм аларның эшчәнлеген булдырмау буенча, шул исәптән әлеге оешмаларны финанслауны булдырмау буенча Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе белән берлектә чаралар комплексын үткәрүне тәэмин итүне;

2) халыкара һәм башка террорчылык һәм экстремистлык оешмалары эшчәнлеген нейтральләштерү һәм аларны законда билгеләнгән җаваплылыкка тарту максатында әлеге оешмаларда катнашучыларга карата актив һәм эзлекле чаралар үткәрүне дәвам итүне;

3) кызыксынучы структуралар белән даими нигездә экстремистлык төсмерендәге янаулар турында дәлилләүче мәгълүмат алмашуны гамәлгә ашыруны һәм бу хакта Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына үз вакытында хәбәр итүне;

4) халык арасында экстремистлык идеологиясен тарату фактларын булдырмауга, милләтара һәм конфессияара дошманлык тудыручы гамәлләргә юл куймауга юнәлдерелгән өстәмә чаралар комплексын җирле үзидарә органнары белән берлектә гамәлгә ашыруны;

5) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән берлектә Татарстан Республикасында этноконфессиональ хәл буенча даими мониторинг үткәрүне оештыруны һәм аның нәтиҗәләрен комплекслы анализлау нигезендә тискәре күренешләрне үз вакытында ачыклауны һәм аларның артуын фаразлауны, ихтимал террорчылык һәм экстремистлык чагылышлары куркынычын бетерүгә юнәлдерелгән тиешле тәкъдимнәр, шул исәптән федераль законнарны һәм республика законнарын камилләштерү буенча, әзерләүне һәм Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертүне.

9. «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы кызыксынучы оешмалар белән берлектә традицион дини кыйммәтләрне, дини түзеп торучанлыкны, дини һәм милли экстремистлыкка каршы көрәшне пропагандалау буенча эш планы әзерләргә, шул исәптән Татарстан Республикасында конфессияләр эшчәнлеге турында абруйлы дин әһелләре һәм галимнәр катнашында теле- һәм радиотапшырулар циклы, шулай ук бу мәсьәлә буенча матбугатта аларның мәкаләләрен бастырып чыгаруны оештырырга тиеш.

2012 елның 1 декабренә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына башкарылган эш турында мәгълүмат тапшырырга тиеш.

10. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаменты, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы югары уку йортлары ректорлары советы һәм Татарстан Республикасы урта махсус уку йортлары директорлары советы Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затларны, дәүләт граждан хезмәткәрләрен, муниципаль хезмәткәрләрне яңадан әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү, югары уку йортлары студентларын һәм урта махсус уку йортлары укучыларын укыту программаларына толерантлыкка бәйле һәм террорчылыкка, экстремистлыкка каршы көрәшкә бәйле мәсьәләләрне кертергә тиеш.

11. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары А.П. Гусевка йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 3 августы
№ 2335-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1151. «Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 7405-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

«Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 7405-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 3 августы
№ 2336-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 1152. «Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (7405-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (7405-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республкасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 3 августы
№ 2337- IV ДС

# II
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 1153. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының чираттан тыш утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының чираттан тыш утырышын 2012 елның 3 августында 10.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утырышлар залында чакырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 1 августы
№ 2326-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 1154. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2012 елның 3 августындагы чираттан тыш утырышы каравына кертелүче мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2012 елның 3 августындагы чираттан тыш утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасында дини экстремистлыкны профилактикалауның һәм аңа каршы көрәшнең торышы һәм чаралары турында.

2. «Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакын-

да» 7405-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 1 августы
№ 2327-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 1155. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2012 елның 3 августындагы чираттан тыш утырышын телевидение һәм радио аша турыдан-туры трансляцияләү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2012 елның 3 августындагы чираттан тыш утырышын телевидение һәм радио аша турыдан-туры трансляцияләүне оештырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2012 елның 1 августы
№ 2328-IV ДС

# III
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЛАРЫ ҺӘМ БОЕРЫКЛАРЫ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

**1156. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында**

Нәтиҗәле хезмәте, Татарстан Республикасы белән Казахстан Республикасы арасындагы сәүдә-икътисадый һәм мәдәни хезмәттәшлекне үстерүгә лаеклы өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасының Казахстан Республикасындагы Тулы вәкаләтле вәкиле урынбасары | Аблаков Рафаил Гәрәй улын |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 02 август
№ ПУ-633

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

**1157. «Татарстан Республикасының Атказанган транспорт хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында**

Күпьеллык  намуслы хезмәте, Татарстан Республикасында граждан авиациясен үстерүгә зур шәхси өлеше өчен

| | |
|---|---|
| «БИГЕШ» АЭРОПОРТЫ» ачык акционер җәмгыяте генераль директорының беренче урынбасары - производство директоры | Ваһапов Валерий Шамил улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган транспорт хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 02 август
№ ПУ-634

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1158. Татарстан Республикасының Әтнә районы Иске Өҗем авылы территориясендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга иминлексезлеге сәбәпле урнаштырылган карантинны бетерү турында

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм**:

1. Терлекләр котыру авырулы булганга иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә:

а) Татарстан Республикасы Әтнә районының Иске Өҗем авылы территориясендә;

б) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә:

Арча районы Арча шәһәренең Бәширов урамында;

«Ясная Поляна» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Алексеевск районы Новоспасск авылы янындагы мөгезле эре терлек асрау өчен файдаланылучы җәйге лагере территориясендә.

2. Түбәндәгеләрнең үз көчләрен югалтуын танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Арча районының аерым территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2012 елның 17 маендагы ПУ-352 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Әтнә районының Иске Өҗем авылы территориясендә һәм Алексеевск районының аерым территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2012 елның 18 маендагы ПУ-357 номерлы Указы.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 03 август
№ ПУ-637

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 1159. Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында

Терлекләрнең котыру авырулы булуы ачыклану һәм аның Татарстан Республикасы торак пунктларында таралу куркынычы белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының $3^1$, 17 статьялары нигезендә **карар бирәм**:

1. Терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле Татарстан Республикасының түбәндәге торак пунктлары территорияләрендә карантин кертергә:

Сарман районының  Карашай-Саклау авылы;

Балтач районының Чапшар авылы.

2. Әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә карантин гамәле дәвам иткән вакытта түбәндәгеләр тыела:

йорт хайваннарын сату, аларны әлеге территориядән читкә чыгару;

котыру авырулы яисә авыру дигән шик тудыра торган хайваннарны ит өчен сую;

котыру авырулы терлекләрнең сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә пастеризацияләнмәгән сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә дезинфекцияләнмәгән йонын, тиресен әлеге территориядән чыгару.

3. Карантин, зарури чаралар күрү шарты үтәлгәндә, терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагы көненнән ике ай вакыт узгач бетерелергә тиеш, дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә терлекләрнең котыру белән чирләвен бетерү буенча чаралар планнарын эшләргә һәм расларга, шулай ук аның гамәлгә ашырылуын тәэмин итәргә.

5. Әлеге Указның үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 03 август
№ ПУ-638

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 1160. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Күпьеллык намуслы хезмәте һәм тимер юл транспорты эшенең нәтиҗәлеген арттыруга зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «Содружество» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры | Белов Иван Алексеевичны |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 03 август
№ ПУ-639

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 1161. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексын үстерүгә лаеклы өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «Дусым» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Директорлар советы рәисе, Әтнә муниципаль районы | Сабиров Наил Закир улын |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 03 август
№ ПУ-640

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1162. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы структурасына үзгәреш кертү турында

Россия Федерациясе гражданнарының сәламәтлеген саклау өлкәсендә туган мөнәсәбәтләрне җайга салучы Россия Федерациясе законнарына үзгәрешләр керү, шулай ук Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 26 декабрендәге ПУ-699 номерлы Указы белән хупланган (Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 14 декабрендәге ПУ-809 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы структурасына, кушымтада бирелгән яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үзенең хокукый актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыру өчен кирәкле башка карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 04 август
№ ПУ-641

Татарстан Республикасы
Президентының
2012 елның «04» августындагы
ПУ-641 номерлы Указына кушымта

# Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы структурасы

**Эшләр идарәсе**
- Секретариат
- Гомуми бүлек
- Гражданнар хатлары һәм мөрәҗәгатьләре белән эшләү секторы
- Мәгълүмати һәм инновацияле технологияләр бүлеге

**Министрның беренче урынбасары**

**Медицина эшчәнлеге стандартларын һәм сыйфатын контрольдә тоту идарәсе**
- Медицина эшчәнлеге һәм медицина экспертизалары сыйфатын контрольдә тоту ведомство бүлеге
- Стандартларны кертү һәм мониторинглау бүлеге
- «Сәламәтлек» милли проектын гамәлгә ашыру секторы

**Югары технологияле медицина ярдәмен оештыру бүлеге**

**Казан, Чаллы, Әлмәт һәм Түбән Кама шәһәрләрендәге территориаль идарәләр**

**Министр урынбасары**

**Икътисадый анализ һәм фараз идарәсе**
- Бюджет акчалары буенча икътисадый анализ бүлеге
- Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе чаралары буенча икътисадый анализ бүлеге
- Дәүләт гарантияләре программасын хисаплау бүлеге

**Махсус программалар һәм проектлар эшләү һәм гамәлгә ашыру бүлеге**

**Бюджеттан тыш сәламәтлек саклау секторы**

**Министр**

**Ярдәмче**

**Пресс-секретарь**

**Министр урынбасары**

**Дәвалау һәм профилактика ярдәме белән идарә итү**
- Дәвалау ярдәме бүлеге
- Балаларга медицина ярдәме күрсәтүне оештыру, хатын-кызларга бала тудыруда һәм тудыргач ярдәм итү хезмәте бүлеге
- Профилактик ярдәм һәм сәламәтлекне ныгыту бүлеге

**Кадрлар бүлеге**

**Медицина хезмәткәрләрен аттестацияләү һәм аларның квалификациясен күтәрү секторы**

**Министр урынбасары**

**Фармация идарәсе**
- Дарулар белән тәэмин итүгә идарә бүлеге
- Дару чаралары әйләнеше өлкәсендә җайга салу бүлеге
- Дәүләт заказын җайга салу бүлеге

**Медицина техникасы бүлеге**

**Икенче бүлек**

**Юридик бүлек**

**Министр урынбасары**

**Лицензияләр бирү идарәсе**
- Медицина эшчәнлеген лицензияләү бүлеге
- Фармация эшчәнлеге һәм наркотик чаралар, психотроп матдәләр, прекурсорлар әйләнеше, составында наркотик матдәләр булган үсемлекләр үстерү белән бәйле эшчәнлекне лицензияләү бүлеге
- Сәламәтлек саклауның беренчел буынын үстерү секторы

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1163. Б.И. Исмәгыйлевны Татарстан Республикасы Президентының Эксперт идарәсе башлыгы итеп билгеләп кую турында

Исмәгыйлев Булат Ибраһим улын Татарстан Республикасы Президентының Эксперт идарәсе башлыгы итеп билгеләп куярга.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 07 август
№ ПУ-642

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1164. Татарстан Республикасының Балтач районы Көек авылы территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга иминлексезлегә сәбәпле урнаштырылган карантинны бетерү турында

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Балтач районы Көек авылы территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының  Балтач районы Көек авылы территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2012 елның 30 маендагы ПУ-404 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 10 август
№ ПУ-643

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 1165. Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасы Балтач районының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында

Терлекләрнең котыру авырулы булуы ачыклану һәм аның Татарстан Республикасы торак пунктларында таралу куркынычы белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының $3^1$, 17 статьялары нигезендә **карар бирәм**:

1. Терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертергә:

а) Татарстан Республикасының түбәндәге торак пунктлары территорияләрендә:

Балтач районының Сасна Пүчинкәсе авылы;

Түбән Кама районының Шәңгәлче авылы;

б) Татарстан Республикасы Балтач районының түбәндәге аерым территорияләрендә:

Борбаш авылының Пионер урамы;

Урта Көшкәт авылының Депутат урамы.

2. Әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә карантин гамәле дәвам иткән вакытта түбәндәгеләр тыела:

йорт хайваннарын сату, аларны әлеге территориядән читкә чыгару;

котыру авырулы яисә авыру дигән шик тудыра торган хайваннарны ит өчен сую;

котыру авырулы терлекләрнең сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә пастеризацияләнмәгән сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә дезинфекцияләнмәгән йонын, тиресен әлеге территориядән чыгару.

3. Карантин, зарури чаралар күрү шарты үтәлгәндә, терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагы көненнән ике ай вакыт узгач бетерелергә тиеш, дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә терлекләрнең котыру белән чирләвен бетерү буенча чаралар планнарын эшләргә һәм расларга, шулай ук аның гамәлгә ашырылуын тәэмин итәргә.

5. Әлеге Указның үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 10 август
№ ПУ-644

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1166. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның акчалата бүләкләүләрен индексацияләү турында

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларны «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларны акчалата бүләкләү турында» 2006 елның 27 мартындагы ПУ-122 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2006 елның 29 декабрендәге ПУ-597 номерлы, 2007 елның 12 октябрендәге ПУ-538 номерлы, 2008 елның 28 апрелендәге ПУ-168 номерлы, 2010 елның 6 маендагы ПУ-295 номерлы, 2010 елның 15 июлендәге ПУ-461 номерлы, 2010 елның 2 сентябрендәге ПУ-585 номерлы, 2011 елның 21 апрелендәге ПУ-230 номерлы һәм 2011 елның 6 августындагы ПУ-480 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) билгеләнгән һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларны акчалата бүләкләүне индексацияләү турында» 2008 елның 4 сентябрендәге ПУ-442 номерлы һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның акчалата бүләкләүләрен индексацияләү турында» 2008 елның 29 октябрендәге ПУ-544 номерлы указлары белән арттырылган (индексацияләнгән) акчалата

бүләкләүне 2012 елның 1 октябреннән 1,06 тапкыр күтәрергә (индексацияләргә).

2. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның акчалата бүләкләвен күтәргәндә (индексацияләгәндә) аның күләме, шулай ук айлык акчалата бүләкләү күләме арттыру ягына тулы бер сумга кадәр түгәрәкләнергә тиеш, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны, Татарстан Республикасы бюджетында тиешле финанс елына караган бюджет ассигнованиеләре күләмендә финанслауны тормышка ашырырга.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 13 август
№ ПУ-645

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1167. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 23 статьясындагы 12 өлеше нигезендә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең акчалата гомуми хезмәт хакы турында» 2006 елның 5 апрелендәге ПУ-133 номерлы (Татарстан Республикасы Президентының 2006 елның 25 декабрендәге ПУ-583 номерлы, 2010 елның 15 июлендәге ПУ-459 номерлы, 2011 елның 22 апрелендәге ПУ-234 номерлы, 2011 елның 20 июнендәге ПУ-360 номерлы, 2011 елның 13 октябрендәге ПУ-646 номерлы һәм 2012 елның 20 февралендәге ПУ-126 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппаратында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның вазыйфаи окладлары турында» 2006 елның 5 апрелендәге ПУ-142 номерлы (Татарстан

Республикасы Президентының 2010 елның 13 мартындагы ПУ-128 номерлы, 2010 елның 19 апрелендәге ПУ-238 номерлы, 2010 елның 21 июнендәге ПУ-394 номерлы, 2010 елның 8 сентябрендәге ПУ-596 номерлы, 2011 елның 13 апрелендәге ПУ-210 номерлы, 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-620 указлары һәм 2011 елның 30 ноябрендәге ПУ-774 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) указлары белән билгеләнгән һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында» 2007 елның 3 декабрендәге ПУ-647 номерлы һәм «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында» 2008 елның 3 октябрендәге ПУ-490 номерлы Указы нигезендә арттырылган (индексацияләнгән) айлык вазыйфаи окладларын, алар биләгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларына туры китереп, 2012 елның 1 октябреннән 1,06 тапкыр күтәрергә (индексацияләргә).

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең, алар биләгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларына туры китереп, айлык вазыйфаи окладларын күтәргәндә (индексацияләгәндә) аларның күләме, шулай ук айлык һәм башка өстәлмәләр һәм өстәмә түләүләр күләме арттыру ягына тулы бер сумга кадәр түгәрәкләнергә тиеш, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны Татарстан Республикасы бюджетында тиешле финанс елына караган бюджет ассигнованиеләре күләмендә финанслауны тормышка ашырырга.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 13 август
№ ПУ-646

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1168. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник тәэмин итүне тормышка ашыручы хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник тәэмин итүне һәм аларга хезмәт күрсәтүне тормышка ашыручы хезмәткәрләргә социаль гарантияләр тәэмин итү максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник тәэмин итүне һәм аларга хезмәт күрсәтүне тормышка ашыручы хезмәткәрләрнең Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник тәэмин итүне һәм аларга хезмәт күрсәтүне тормышка ашыручы хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2006 елның 16 июнендәге ПУ-221 номерлы (Татарстан Республикасы Президентының 2007 елның 28 февралендәге ПУ-117 номерлы, 2008 елның 23 гыйнварындагы ПУ-19 номерлы, 2010 елның 9 февралендәге ПУ-48 номерлы һәм 2011 елның 13 октябрендәге ПУ-646 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары турында» 2006 елның 16 июнендәге (Татарстан Республикасы Президенты 2008 елның 29 августындагы ПУ-425 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) указлары белән билгеләнгән һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник тәэмин итүне тормышка ашы-

ручы хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында» 2008 елның 23 гыйнварындагы ПУ-19 номерлы һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник тәэмин итүне тормышка ашыручы хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында» 2008 елның 3 октябрендәге ПУ-491 номерлы указлары белән арттырылган (индексацияләнгән) вазыйфаи окладлары күләмнәрен 2012 елның 1 октябреннән 1,06 тапкыр күтәрергә (индексацияләргә).

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник тәэмин итүне тормышка ашыручы хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын күтәргәндә (индексацияләгәндә) аларның күләме, шулай ук айлык һәм башка өстәлмәләр һәм өстәмә түләүләр күләме арттыру ягына бөтен бер сумга кадәр түгәрәкләнергә тиеш, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны Татарстан Республикасы бюджетында тиешле финанс елына каралган бюджет ассигнованиеләре күләмендә финанслауны тормышка ашырырга.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 13 август
№ ПУ-647

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1169. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгын бетерү турында

Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте башкарма органнары структурасын камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Конституциясенең 94 статьясы, «Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте башкарма органнары турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә **карар бирәм**:

1. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгын бетерергә.

2. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы бетерелү сәбәпле, аның матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге дәүләт идарәсе мәсьәләләре буенча функцияләрен Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына тапшырырга.

3. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы бетерелү сәбәпле, аның хокуклары, шул исәптән төзегән килешүләре һәм шартнамәләре нигезендә туган йөкләмәләре буенча, шулай ук суд карарлары нәтиҗәсендә туган йөкләмәләре буенча да, Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына күчә дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте башкарма органнары структурасы турында» 2010 елның 22 апрелендәге ПУ-254 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 25 декабрендәге ПУ-863 номерлы, 2011 елның 5 мартындагы ПУ-108 номерлы, 2011 елның 1 июнендәге ПУ-298 номерлы, 2011 елның 25 октябрендәге ПУ-676 номерлы, 2012 елның 10 мартындагы ПУ-189 номерлы һәм 2012 елның 28 маендагы ПУ-395 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән), Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары структурасының IV бүлегендәге «Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы» абзацын төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

5. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте составына керүче вазыйфаи затлар исемлеге турында» 2010 елның 22 апрелендәге ПУ-255 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 21 апрелендәге ПУ-231, 2011 елның 1 июнендәге ПУ-298, 2012 елның 10 мартындагы ПУ-189 номерлы һәм 2012 елның 23 маендагы ПУ-363 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән), «Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе» дигән абзацны төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

ликвидацияләү комиссиясе төзергә һәм Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгын бетерүгә бәйле, шул исәптән ликвидацияләү процедурасын

законнарда каралган срокларда уздыру буенча чаралар комплексын гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә;

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы бетерелү сәбәпле, аның функцияләрен әлеге Указ нигезендә тапшыруны тәэмин итәргә һәм аларны башкару өчен кирәкле чик штат санын билгеләргә;

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы бетерелү сәбәпле, оештыру-штат чараларын тәмамлаганчы, аның дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм башка эшчеләренә матди тәэминатның һәм законнарда каралган ташламалар һәм гарантияләр бирүнең гамәлдәге тәртибен сакларга;

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының бетерелүе сәбәпле эштән азат ителә торган дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм аның башка эшчеләренә законнар нигезендә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне тәэмин итәргә;

кирәк булганда, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының бетерелүенә бәйле закон проектлары кертергә;

ике ай вакыт эчендә Татарстан Республикасы Президенты актларына әлеге Указ нигезендә үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәр кертергә;

үз актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

7. Татарстан Республикасы Президентының «Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы турында» 2009 елның 15 маендагы ПУ-278 номерлы Указының 1-6 пунктларын үз көчләрен югалтты дип танырга.

8. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 13 август
№ ПУ-648

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 1170. Татарстан Республикасы Президенты Аппараты структурасына һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президенты Аппаратында Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең беренче урынбасары –Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын гамәлгә куярга.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестры турында» 2006 елның 18 гыйнварындагы ПУ-9 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 12 мартындагы ПУ-121 номерлы, 2010 елның 1 апрелендәге ПУ-183 номерлы, 2010 елның 10 июнендәге ПУ-378 номерлы, 2010 елның 30 июнендәге ПУ-416 номерлы, 2010 елның 3 августындагы ПУ-512 номерлы, 2010 елның 2 сентябрендәге ПУ-585 номерлы, 2011 елның 31 гыйнварындагы ПУ-34 номерлы, 2011 елның 20 июлендәге ПУ-360 номерлы, 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-620 номерлы, 2011 елның 13 октябрендәге ПУ-646 номерлы, 2011 елның 30 ноябрендәге ПУ-774 номерлы, 2012 елның 20 февралендәге ПУ-126 номерлы һәм 2012 елның 24 маендагы ПУ-375 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестрының 1 кисәгендәге 1 бүлегенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

| | |
|---|---|
| « Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәчесе | 01-1-1-01» |

позициясеннән соң:

| | |
|---|---|
| « Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең беренче урынбасары | 01-1-1-01[1]». |

позициясен өстәргә.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппаратында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләгән затларның вазыйфаи окладлары турында» 2006 елның 5 апрелендәге ПУ-142 номерлы Указына кушымтага (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 13 мартындагы ПУ-128 номерлы, 2010 елның 19 апрелендәге ПУ-238 номерлы, 2010 елның 21 июнендәге ПУ-394 номерлы, 2010 елның 8 сентябрендәге ПУ-596 номерлы һәм 2011 елның 30 ноябрендәге ПУ-774 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән), Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында» 2007 елның 3 декабрендәге ПУ-647 номерлы һәм «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында» 2008 елның 3 октябрендәге ПУ-490 номерлы указларының нигезләмәләрен исәпкә алып, түбәндәге үзгәрешне кертергә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| « | Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәчесе | 01-1-1-01 | 9090 | » |

позициясеннән соң түбәндәге эчтәлекле:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| « | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең беренче урынбасары | 01-1-1-01$^{1}$ | 9090 | » |

позициясен өстәргә.

4. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының гомуми санын раслау турында» 2008 елның 23 июнендәге ПУ-300 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 5 мартындагы ПУ-124 номерлы, 2009 елның 13 июнендәге ПУ-328 номерлы, 2009 елның 13 ноябрендәге ПУ-606 номерлы, 2009 елның 17 ноябрендәге ПУ-611 номерлы, 2010 елның 22 мартындагы ПУ-158 номерлы, 2010 елның 21 апрелендәге ПУ-253 номерлы, 2010 елның 10 июнендәге ПУ-378 номерлы, 2010 елның 3 августындагы ПУ-512 номерлы, 2010 елның 11 октябрендәге ПУ-681 номерлы, 2010 елның 1 ноябрендәге ПУ-712 номерлы, 2010 елның 23 декабрендәге ПУ-

855 номерлы, 2011 елның 15 гыйнварындагы ПУ-7 номерлы, 2011 елның 31 гыйнварындагы ПУ-33 номерлы, 2011 елның 3 февралендәге ПУ-42 номерлы, 2011 елның 23 мартындагы ПУ-143 номерлы, 2011 елның 11 апрелендәге ПУ-194 номерлы, 2011 елның 29 июлендәге ПУ-459 номерлы, 2011 елның 19 августындагы ПУ-508 номерлы, 2011 елның 5 сентябрендәге ПУ-543 номерлы, 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-620 номерлы, 2011 елның 13 октябрендәге ПУ-646 номерлы, 2011 елның 25 октябрендәге ПУ-676 номерлы, 2011 елның 25 октябрендәге ПУ-677 номерлы, 2011 елның 25 ноябрендәге ПУ-748 номерлы, 2011 елның 30 ноябрендәге ПУ-774 номерлы, 2012 елның 18 гыйнварындагы ПУ-23 номерлы, 2012 елның 10 мартындагы ПУ-190 номерлы, 2012 елның 13 апрелендәге ПУ-257 номерлы, 2012 елның 11 июнендәге ПУ-460 номерлы, 2012 елның 23 июнендәге ПУ-495 номерлы, 2012 елның 27 июлендәге ПУ-622 номерлы һәм 2012 елның 30 июлендәге ПУ-624 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) 1 нче кушымтага, 1 пункттагы «188» санын «190» санына алмаштырып, үзгәреш кертергә.

5. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты турында нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 20 мартындагы ПУ-114 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 12 мартындагы ПУ-121 номерлы, 2010 елның 1 апрелендәге ПУ-183 номерлы һәм 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-622 номерлы һәм 2011 елның 30 ноябрендәге ПУ-774 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президенты Аппараты турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 8 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе һәм аның урынбасарлары» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең беренче урынбасары һәм урынбасарлары» сүзләренә алмаштырырга;

б) 12 пункның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе,» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең беренче урынбасары,» сүзләрен өстәргә;

в) 15 пунктта «Аппарат» сүзеннән соң «җитәкчесенең беренче» сүзләрен өстәргә.

6. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты турында» 2006 елның 5 апрелендәге ПУ-134 номерлы Указының (Татарстан Республикасы Президентының 2006 елның 16 июнендәге ПУ-223 номерлы, 2006 елның 10 ноябрендәге ПУ-466 номерлы, 2007 елның 21 июнендәге ПУ-323 номерлы, 2008 елның 29 августындагы ПУ-425 номерлы, 2010 елның 12 мартындагы ПУ-121 номерлы, 2010 елның 1 апрелендәге ПУ-183 номерлы, 2010 елның 12 июлендәге ПУ-445 номерлы, 2010 елның 25 декабрендәге ПУ-863 һәм 2011 елның 15 гыйнварындагы ПУ-7 номерлы һәм 2011 елның 30 ноябрендәге ПУ-774 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) 1 пунктындагы беренче абзацына, «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе һәм аның урынбасарлары» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең беренче урынбасары һәм урынбасарлары» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

7. Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-620 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 30 ноябрендәге ПУ-774 номерлы, 2012 елның 18 гыйнварындагы ПУ-24 номерлы, 2012 елның 10 мартындагы ПУ-188 номерлы, 2012 елның 11 июлендәге ПУ-559 номерлы, 2012 елның 16 июлендәге ПУ-587 номерлы һәм 2012 елның 30 июлендәге ПУ-624 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президенты Аппараты структурасына һәм хезмәткәрләренең чик санына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а)

«

| | | | |
|---|---|---|---|
| **1.** | **Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе** | **1** | |

»

позициясен түбәндәге эчтәлекле позицияләргә алмаштырырга:

«

| | | | |
|---|---|---|---|
| **1.** | **Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе** | **1** | |
| **1[1]** | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең беренче урынбасары | 1 | |

»;

б) Татарстан Республикасы Президенты Аппараты хезмәткәрләре структурасы һәм чик санының 1-8 позициясе буенча

«Барлыгы» позициясенең «Берәмлекләр саны» графасында «15» санын «16» санына алмаштырырга;

в)

«

| | | | |
|---|---|---|---|
| **83.** | Баш белгеч | 2 | |

»

позициясен түбәндәге эчтәлекле

«

| | | | |
|---|---|---|---|
| **83.** | Баш белгеч | 3 | |

»;

позициясенә алмаштырырга.

г) «Идарә буенча барлыгы» позициясенең «Берәмлекләр саны» графасында Татарстан Республикасы Президентының Документлар белән тәэмин итү һәм контроль идарәсе буенча «11» санын «12» санына алмаштырырга;

д)

«

| | | | |
|---|---|---|---|
| | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ БУЕНЧА БАРЛЫГЫ** | 198 | |

»

позициясен түбәндәге эчтәлекле

«

| | | | |
|---|---|---|---|
| | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ БУЕНЧА БАРЛЫГЫ** | 200 | |

»

позициясенә алмаштырырга.

8. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 13 август
№ ПУ-649

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 1171. М.Я. Моратовны Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең беренче урынбасары итеп билгеләп кую турында

Моратов Марат Яшәр улын, аны элек биләгән вазыйфасыннан азат итеп, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең беренче урынбасары итеп билгеләп куярга.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 13 август
№ ПУ-650

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 1172. М.И. Гатинны Татарстан Республикасы Президентының Дини берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлек идарәсе башлыгы вазыйфасыннан азат итү турында

Гатин Марат Илшат улын, башка эшкә күчүе сәбәпле, Татарстан Республикасы Президентының Дини берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлек идарәсе башлыгы вазыйфасыннан азат итәргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 13 август
№ ПУ-651

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 1173. Татарстан Республикасы Президентының аерым актларына үзгәрешләр кертү турында

Кайбер затларның башка эшкә күчүләре белән бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Ел җитәкчесе» республика җәмәгать конкурсы турында» 2002 елның 26 февралендәге ПУ-121 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2003 елның 12 мартындагы ПУ-201 номерлы, 2004 елның 25 мартындагы ПУ-223 номерлы, 2005 елның 21 февралендәге ПУ-57 номерлы, 2005 елның 30

июнендәге ПУ-274 номерлы, 2006 елның 19 гыйнварындагы ПУ-12 номерлы, 2006 елның 17 мартындагы ПУ-111 номерлы, 2007 елның 12 октябрендәге ПУ-537 номерлы, 2008 елның 26 ноябрендәге ПУ-602 номерлы, 2009 елның 17 апрелендәге ПУ-202 номерлы, 2010 елның 7 октябрендәге ПУ-665 номерлы, 2010 елның 9 декабрендәге ПУ-800 номерлы һәм 2011 елның 15 сентябрендәге ПУ-564 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган «Ел җитәкчесе» республика җәмәгать конкурсы комиссиясе (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан Р.Ф. Әбүбәкеровны, И.М. Гариповны, Н.А. Никифоровны, Ә.Ә. Сәфәровны, И.Ш. Фәрдиевны чыгарырга;

б) Комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Хәйруллин Айрат Ринат улын – Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесен;

Шәйхетдинов Роман Александровичны – Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрын;

Шакиров Минсәгыйть Закир улын – Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы рәисен (килешү буенча).

2. Татарстан Республикасы Президентының «Бөтендөнья финанс кризисы шартларында Татарстан Республикасы икътисады үсешен тәэмин итү республика комиссиясе турында» 2008 елның 29 декабрендәге ПУ-696 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 14 апрелендәге ПУ-186 номерлы, 2009 елның 22 июнендәге ПУ-344 номерлы, 2010 елның 15 июнендәге ПУ-382 номерлы һәм 2010 елның 20 августындагы ПУ-547 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Бөтендөнья финанс кризисы шартларында Татарстан Республикасы икътисады үсешен тәэмин итү республика комиссиясе (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан М.М. Галимәрдановны, А.В. Красновны, Ә.Ә. Сәфәровны, М.А. Фәйрушинаны, И.Ш. Фәрдиевны, М.Ш. Хөснуллинны, Т.Н. Шаһивәлиевны чыгарырга;

б) Комиссия составына кертергә:

Зарипов Марат Рифгать улын - Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисен;

Идрисов Рөстәм Фидаи улын – Татарстан Республикасы буенча баш федераль инспекторны (килешү буенча);

Фәйзуллин Ирек Әнвәр улын – Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрын;

Хаҗиев Раузил Мәгъсүмҗан улын – «Генерацияләүче компания» ачык акционер җәмгыяте генераль директорын (килешү буенча);

Хәйруллин Айрат Ринат улын – Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесен;

Якупов Линар Габделнур улын – Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесен.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткәндә гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чаралары турында» 2010 елның 5 апрелендәге ПУ-203 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 6 июлендәге ПУ-429 номерлы һәм 2011 елның 7 февралендәге ПУ-47 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткәндә гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү буенча республика ведомствоара комиссиясе (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан А.Н. Беловны, Л.С. Вәлиевны, Г.И. Сергееваны, Ф.Х. Туктаровны, Р.М. Хаҗиевны чыгарырга;

б) Комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Зарипов Марат Рифгать улын – Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисен, аны Комиссия рәисе урынбасары итеп расларга;

Салихов Фаил Фатыйх улын – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә башкарма органнары хезмәттәшлеген оештыру бүлеге башлыгын;

Фролов Алексей Михайловичны – Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министры урынбасарын.

4. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында азык-төлек продуктларына бәяләрне тотрыклыландыру буенча эш төркеме төзү турында» 2007 елның 22 октябрендәге 285 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 17 апрелендәге 101 номерлы һәм 2010 елның 13 декабрендәге 406 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында азык-төлек продуктларына бәяләрне тотрыклыландыру буенча эш төркеме (алга таба - эш төркеме) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) эш төркеме составыннан Р.Ф. Әбүбәкеровны, М.М. Галимәрдановны, А.В. Красновны, В.В. Морозовны, Ә.Ә. Сәфәровны чыгарырга;

б) эш төркеме составына кертергә:

Идрисов Рөстәм Фидаи улын – Татарстан Республикасы буенча баш федераль инспекторны (килешү буенча);

Патяшина Марина Александровнаны – Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе җитәкчесен;

Хәйруллин Айрат Ринат улын – Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесен;

Шакиров Минсәгыйть Закир улын – Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы рәисен (килешү буенча).

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 14 август
№ ПУ-652

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1174. «Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Татар халкының мәдәни, рухи-әхлакый традицияләрен саклап калуга һәм үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге Тулы вәкаләтле вәкиллеге каршындагы иҗтимагый совет рәисе | Мириханов Назиф Мөҗәһидән улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 14 август
№ ПУ-653

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1175. «Татарстан Республикасының Атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык намуслы хезмәте, яшь буынга белем һәм тәрбия бирү өлкәсендәге казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| Мамадыш муниципаль районы «Зур Шыя урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең мари теле һәм әдәбияты укытучысы | Дмитриева Светлана Лукояновнага |

«Татарстан Республикасының Атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 14 август
№ ПУ-655

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1176. «Татарстан Республикасының Атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык намуслы хезмәте һәм Татарстан Республикасының төзелеш тармагын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «Каздорстрой» ачык акционер җәмгыятенең производство-техник бүлеге башлыгы | Тропынина Ольга Станиславовнага |

«Татарстан Республикасының Атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 14 август
№ ПУ-656

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1177. «Татарстан Республикасының Атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык намуслы хезмәте һәм Татарстан Республикасының төзелеш комплексын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «Татарстан Республикасының Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе производство бүлеге баш белгече | Галимов Шәфкать Мөхәммәтзәки улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 14 август
№ ПУ-657

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1178. «Татарстан Республикасының Атказанган физик культура хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Физик культура һәм спортны үстерүгә лаеклы өлеш кертүе, Лондондагы XXX җәйге Олимпия уеннарының стендта ату буенча бронза призерын әзерләве өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасының Ядрә белән һәм стендта ату федерациясе президенты, Татарстан Республикасы яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгының стендта ату буенча «Олимпия резервының республика махсуслаштырылган балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» балаларга өстәмә белем бирү дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе директоры | Демин Сергей Константиновичка |

«Татарстан Республикасының Атказанган физик культура хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 15 август
№ ПУ-658

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1179. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Физик культура һәм спортны үстерүгә лаеклы өлеш кертүе, Лондондагы XXX җәйге Олимпия уеннарының фехтование буенча көмеш призерын әзерләве өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгының «Фехтование буенча олимпия резервының республика махсуслаштырылган балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» балаларга өстәмә белем бирү дәүләт автоном учреждениесе директоры | Шәймәрданов Илдар Равил улын |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 15 август
№ ПУ-659

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1180. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Физик культура һәм спортны үстерүгә лаеклы өлеш кертүе, Лондондагы XXX җәйге Олимпия уеннарының синхрон йөзү буенча чемпионын әзерләве өчен

| | |
|---|---|
| Россиянең синхрон йөзү буенча җыелма командасы баш тренеры, Россиянең синхрон йөзү федерация-се вице-президенты | Покровская Татьяна Николаевнаны |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» ме-дале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 15 август
№ ПУ-660

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 1181. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Лондондагы XXX җәйге Олимпия уеннарында югары спорт күрсәткечләренә ирешүләре өчен:

| | |
|---|---|
| атказанган спорт мастеры, Олимпия уеннарының фехтование буенча көмеш призеры | Гафурҗанова Камилла Йосыф кызын |
| атказанган спорт мастеры, Олимпия уеннарының тхэквондо буенча бронза призеры | Денисенко Алексей Алексеевичны |
| атказанган спорт мастеры, Олимпия уеннарының стендта ату буенча бронза призеры | Мосин Василий Александровичны |
| атказанган спорт мастеры, Олимпия уеннарының синхрон йөзү буенча чемпионы | Хәсәнова Эльвира Рамил кызын |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» ме-дале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 15 август
№ ПУ-661

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 1182. «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләү турында

Лондондагы XXX җәйге Олимпия уеннарында гаять югары спорт күрсәткечләренә ирешүләре өчен:

| | |
|---|---|
| Россиянең атказанган спорт мастеры, Олимпия уеннарының җиңел атлетика буенча чемпионы | Зарипова Юлия Михайловнаны |
| Россиянең атказанган спорт мастеры, Олимпия уеннарының волейбол буенча чемпионы | Апаликов Николай Сергеевичны |
| Россиянең атказанган спорт мастеры, Олимпия уеннарының волейбол буенча чемпионы | Бережко Юрий Викторовичны |
| Россиянең атказанган спорт мастеры, Олимпия уеннарының волейбол буенча чемпионы | Волков Александр Александровичны |
| Россиянең атказанган спорт мастеры, Олимпия уеннарының волейбол буенча чемпионы | Михайлов Максим Михайловичны |
| Россиянең атказанган спорт мастеры, Олимпия уеннарының волейбол буенча чемпионы | Обмочаев Алексей Александровичны |

«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 15 август
№ ПУ-662

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1183. «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләү турында

Физик культура һәм спортны үстерүдәге гаять зур казанышлары, Лондондагы XXX җәйге Олимпия уеннары чемпионнарын әзерләве өчен

| | |
|---|---|
| Россиянең волейбол буенча җыелма ирләр командасы баш тренеры, «Зенит» волейбол клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы баш тренеры, Казан шәһәре | Алекно Владимир Романовичны |

«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 15 август
№ ПУ-663

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1184. «Татарстан Республикасының Атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык намуслы хезмәте, мәгариф өлкәсендәге казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| Лениногорск муниципаль районы «Лениногорск шәһәренең 12 нче лицее» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең физик культура укытучысы | Сәфәров Марсиль Мидхәт улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 15 август
№ ПУ-664

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1185. «Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте,Татарстан Республикасында массакүләм мәгълүмат чараларын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «ТАТМЕДИА» ачык акционер җәмгыятенең «Волжские зори» («Идел таңнары») газетасы редакциясе» филиалы директоры | Юманов Виталий Алексеевичка |

«Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 15 август
№ ПУ-665

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1186. «Татарстан Республикасының Атказанган физик культура хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты - КАИ» югары һөнәри белем федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең Түбән Кама мәгълүмат технологияләре һәм телекоммуникацияләр институты (филиалы) физик тәрбия һәм спорт циклы өлкән укытучысы | Коновалов Виталий Павловичка |

«Татарстан Республикасының Атказанган физик культура хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 15 август
№ ПУ-666

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1187. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, Түбән Кама муниципаль районының социаль-икътисадый һәм мәдәни үсешенә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы | Метшин Айдар Рәис улын |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 16 август
№ ПУ-667

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1188. «Татарстан Республикасының Атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, капиталь төзелеш өлкәсендәге казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| «Уют» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры | Хафизов Әмирҗан Әхтәм улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 16 август
№ ПУ-668

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1189. «Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирү турында

Законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы казанышлары, нәтиҗәле фәнни һәм укытучылык эшчәнлеге өчен

| | |
|---|---|
| «Мәскәү гуманитар-икътисад институты» югары профессиональ белем бирү автоном коммерциячел булмаган оешмасының Түбән Кама филиалы хокук дисциплиналары кафедрасы мөдире | Шакиров Хәйдәр Садыйк улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 16 август
№ ПУ-669

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1190. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Буа муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы урынбасары | Усманов Зәкәрия Абдулла улын |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 16 август
№ ПУ-670

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1191. «Татарстан Республикасының Атказанган табибы» дигән мактаулы исем бирү турында

Халык сәламәтлеген саклаудагы казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| «Лучезарный» санаторий-профилакторие» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры, Нурлат шәһәре | Юнысов Азат Исхак улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган табибы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 16 август
№ ПУ-672

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1192. «Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан» медале белән бүләкләү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре һәм нефть сәнәгатен үстерүгә лаеклы өлеш кертүләре өчен:

| | |
|---|---|
| В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ачык акционер җәмгыятенең «Лениногорскнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсе 2 нче нефть һәм газ чыгару цехының нефть һәм газ чыгару буенча операторы | Григорьев Николай Леонидовичны |
| «Татбурнефть» идарә компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте «Бораулау» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте Әлмәт бораулау эшләре предприятиесе скважиналар сынау цехының скважиналарны капиталь төзекләндерү бораулаучысы | Нурморатов Хәлил Ишим улын |

| | |
|---|---|
| «Татспецтранспорт» идарә компаниясе» җавплылыгы чикләнгән җәмгыяте «Татбуртранс» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең автомобиль краны машинисты | Софронов Григорий Аверьяновичны |
| В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ачык акционер җәмгыятенең катламнардан нефть чыгаруны арттыру ысуллары буенча тәҗрибә-промысел эшләре бүлеге башлыгы – катламнардан нефть чыгаруны арттыру ысуллары идарәсе башлыгы урынбасары | Фәрхетдинов Гомәр Нәүфәл улын |

«Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 16 август
№ ПУ-673

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1193. «Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирү турында

Нәтиҗәле хезмәте, Татарстан Республикасының банк системасын үстерүдә һәм камилләштерүдә казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| «Татфондбанк» акционер инвестиция коммерция банкы» ачык акционер җәмгыяте идарә рәисенең беренче урынбасары | Таһирова Наилә Шавкат кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 20 август
№ ПУ-674

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1194. «Татарстан Республикасы Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Сәламәтлек саклау өлкәсендәге казанышлары, күпьеллык намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник онкология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибының оештыру-методик эш буенча урынбасары | Шакиров Камил Тавхит улына |

«Татарстан Республикасы Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 20 август
№ ПУ-676

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1195. «Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Нәтиҗәле хезмәте, Татарстан Республикасында мәдәниятне һәм сәнгатьне үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү бүлеге башлыгы | Нигъмәтуллина Гөлшат Рәдиф кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 20 август
№ ПУ-677

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1196. «Татарстан Республикасының Атказанган машина төзүчесе» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык намуслы хезмәте, югары производство күрсәткечләре һәм илебездә мотор төзү өлкәсен үстерүгә өлеше өчен

| | |
|---|---|
| «Казан мотор төзү производство берләшмәсе» ачык акционер җәмгыятенең тышча белән каплау цехы участок мастеры | Сабирова Ризидә Хәерҗан кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган машина төзүчесе» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 20 август
№ ПУ-678

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1197. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Күпьеллык намуслы хезмәте, банк эшен үстерү һәм камилләштерү өлкәсендәге казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| «Россия саклык банкы» ачык акционер җәмгыятенең 8219 номерлы Чаллы бүлекчәсе идарәчесе урынбасары – 8219/089 номерлы өстәмә (универсаль) офисы мөдире | Әхмаев Таһирҗан Зиннур улын |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 20 август
№ ПУ-679

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 1198. Татарстан Республикасы Президенты Аппараты структурасына һәм хезмәткәрләренең чик санына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-620 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 30 ноябрендәге ПУ-774 номерлы, 2012 елның 18 гыйнварындагы ПУ-24 номерлы, 2012 елның 10 мартындагы ПУ-188 номерлы, 2012 елның 11 июлендәге ПУ-559 номерлы, 2012 елның 16 июлендәге ПУ-587 номерлы, 2012 елның 30 июлендәге ПУ-624 номерлы һәм 2012 елның 13 августындагы ПУ-649 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президенты Аппараты структурасына һәм хезмәткәрләренең чик санына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а)

**«Татарстан Республикасы Президентының**
**Матбугат хезмәте**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 89. | Матбугат хезмәте җитәкчесе | 1 | |
| 90. | Матбугат хезмәте җитәкчесе урынбасары | 1 | |
| 91. | Баш киңәшче | 3 | |
| 92. | Әйдәүче белгеч | 1 | |
| | | | |
| | **Барлыгы** | **6** | |

»

сүзләрен һәм позицияләрен түбәндәге эчтәлекле сүзләргә һәм позицияләргә алмаштырырга:

**«Татарстан Республикасы Президентының**
**Матбугат хезмәте**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 89. | Матбугат хезмәте җитәкчесе | 1 | |
| 90. | Матбугат хезмәте җитәкчесе урынбасары | 2 | |
| 91. | Баш киңәшче | 5 | |
| 92. | Әйдәүче белгеч | 1 | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | **Барлыгы** | **9** | |

»;

б)

«

| | | | |
|---|---|---|---|
| | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ БУЕНЧА БАРЛЫГЫ** | **200** | |

»

позициясен түбәндәге эчтәлекле

«

| | | | |
|---|---|---|---|
| | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ БУЕНЧА БАРЛЫГЫ** | **203** | |

».

позициясенә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының гомуми санын раслау турында» 2008 елның 23 июнендәге ПУ-300 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 5 мартындагы ПУ-124 номерлы, 2009 елның 13 июнендәге ПУ-328 номерлы, 2009 елның 13 ноябрендәге ПУ-606 номерлы, 2009 елның 17 ноябрендәге ПУ-611 номерлы, 2010 елның 22 мартындагы ПУ-158 номерлы, 2010 елның 21 апрелендәге ПУ-253 номерлы, 2010 елның 10 июнендәге ПУ-378 номерлы, 2010 елның 3 августындагы ПУ-512 номерлы, 2010 елның 11 октябрендәге ПУ-681 номерлы, 2010 елның 1 ноябрендәге ПУ-712 номерлы, 2010 елның 23 декабрендәге ПУ-855 номерлы, 2011 елның 15 гыйнварындагы ПУ-7 номерлы, 2011 елның 31 гыйнварындагы ПУ-33 номерлы, 2011 елның 3 февралендәге ПУ-42 номерлы, 2011 елның 23 мартындагы ПУ-143 номерлы, 2011 елның 11 апрелендәге ПУ-194 номерлы, 2011 елның 29 июлендәге ПУ-459 номерлы, 2011 елның 19 августындагы ПУ-508 номерлы, 2011 елның 5 сентябрендәге ПУ-543 номерлы, 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-620 номерлы, 2011 елның 13 октябрендәге ПУ-646 номерлы, 2011 елның 25 октябрендәге ПУ-676 номерлы, 2011 елның 25 октябрендәге ПУ-677 номерлы, 2011 елның 25 ноябрендәге ПУ-748 номерлы, 2011 елның 30 ноябрендәге ПУ-774 номерлы, 2012 елның 18 гыйн-

варындагы ПУ-23 номерлы, 2012 елның 10 мартындагы ПУ-190 номерлы, 2012 елның 13 апрелендәге ПУ-257 номерлы, 2012 елның 11 июнендәге ПУ-460 номерлы, 2012 елның 23 июнендәге ПУ-495 номерлы, 2012 елның 27 июлендәге ПУ-622 номерлы, 2012 елның 30 июлендәге ПУ-624 номерлы һәм 2012 елның 13 августындагы ПУ-649 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) 1 нче кушымтага, 1 пункттагы «190» санын «193» санына алмаштырып, үзгәреш кертергә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 20 август
№ ПУ-680

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1199. Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестры турында» 2006 елның 18 гыйнварындагы ПУ-9 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 12 мартындагы ПУ-121 номерлы, 2010 елның 1 апрелендәге ПУ-183 номерлы, 2010 елның 10 июнендәге ПУ-378 номерлы, 2010 елның 30 июнендәге ПУ-416 номерлы, 2010 елның 3 августындагы ПУ-512 номерлы, 2010 елның 2 сентябрендәге ПУ-585 номерлы, 2011 елның 31 гыйнварындагы ПУ-34 номерлы, 2011 елның 20 июлендәге ПУ-360 номерлы, 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-620 номерлы, 2011 елның 13 октябрендәге ПУ-646 номерлы, 2011 елның 30 ноябрендәге ПУ-774 номерлы, 2012 елның 20 февралендәге ПУ-126 номерлы, 2012 елның 24 маендагы ПУ-375 номерлы һәм 2012 елның 13 августындагы ПУ-649 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестрының 4 кисәгендәге 3 бүлеккә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

« Татарстан Республикасы Дәүләт
комитеты идарәсе составындагы бүлек башлыгы 04-3-3-$29^1$»

позициясеннән соң, түбәндәге эчтәлекле позиция өстәргә:

« Башкарма хакимиятнең башка республика
органы идарәсе составындагы бүлек башлыгы 04-3-3-29$^{2}$».

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең акчалата гомуми хезмәт хакы турында» 2006 елның 5 апрелендәге ПУ-133 номерлы Указына 3 кушымтага (Татарстан Республикасы Президентының 2006 елның 25 декабрендәге ПУ-583 номерлы, 2010 елның 15 июлендәге ПУ-459 номерлы, 2011 елның 22 апрелендәге ПУ-234 номерлы, 2011 елның 20 июнендәге ПУ-360 номерлы, 2011 елның 13 октябрендәге ПУ-646 номерлы һәм 2012 елның 20 февралендәге ПУ-126 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән), Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында» 2007 елның 3 декабрендәге ПУ-647 номерлы һәм «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында» 2008 елның 3 октябрендәге ПУ-490 номерлы указлары нигезләмәләрен исәпкә алып, түбәндәге үзгәрешне кертергә:

«
| | | |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы министрлыгы идарәсе составындагы бүлек башлыгы | 04-3-3-29 | 4510-4920 |

»

позициясеннән соң түбәндәге эчтәлекле позиция өстәргә:

«
| | | |
|---|---|---|
| Башкарма хакимиятнең башка республика органы идарәсе составындагы бүлек башлыгы | 04-3-3-29$^{2}$ | 5261-5739 |

».

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 20 август
№ ПУ-681

## 1200. Татарстан Республикасы Президентының «Созвездие-Йолдызлык» республика фестиваль хәрәкәтенә ярдәм итү буенча чаралар турында» Указына үзгәреш кертү хакында

Аерым затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә һәм «Созвездие-Йолдызлык» республика фестиваль хәрәкәтенә ярдәм итү буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Совет эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм**:

1.Татарстан Республикасы Президентының «Созвездие-Йолдызлык» республика фестиваль хәрәкәтенә ярдәм итү буенча чаралар турында» 2006 елның 29 апрелендәге ПУ-165 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2007 елның 16 июлендәге ПУ-357 номерлы, 2007 елның 17 декабрендәге ПУ-686 номерлы һәм 2009 елның 17 апрелендәге ПУ-208 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән), «Созвездие-Йолдызлык» республика фестиваль хәрәкәтенә ярдәм итү буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Совет составын кушымта нигезендәге яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 20 август
№ ПУ-682

Татарстан Республикасы
Президентының
2012 елның «20» августындагы
ПУ-682 номерлы Указына
кушымта

## «Йолдызлык-Созвездие» республика фестиваль хәрәкәтенә ярдәм итү буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Совет составы

| | |
|---|---|
| Халиков<br>Илдар Шәфкать улы | Татарстан Республикасы<br>Премьер-министры, Совет рәисе |
| Борһанов<br>Рафис Тимерхан улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министры, Совет рәисе урынбасары |
| Кондратьев<br>Андрей Станиславович | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министры урынбасары, Советның җаваплы секретаре |
| Әминов<br>Илшат Юныс улы | «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Бариев<br>Марат Мансур улы | Дәүләт Думасының Физик культура, спорт һәм яшьләр эшләре комитеты рәисенең беренче урынбасары, Россия Олимпия комитеты генераль секретаре (килешү буенча) |
| Богачев<br>Евгений Борисович | Татарстан Республикасы Милли банкы рәисе (килешү буенча) |
| Вәлиев<br>Разил Исмәгыйль улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Вахитов<br>Ростислав Һади улы | Украинада Татарстан Республикасының Сәүдә вәкиллеге җитәкчесе |
| Гайзатуллин<br>Радик Рәүф улы | Татарстан Республикасы финанс министры |
| Гыйльметдинов<br>Альберт Харис улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |

| | |
|---|---|
| Егоров<br>Иван Михайлович | «Ак Барс холдинг компаниясе» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Лаврентьев<br>Александр Петрович | «Татарстан Республикасы Предприятиеләр һәм эшкуарлар ассоциациясе» төбәк эш бирүчеләр берләшмәсе президенты<br>(килешү буенча) |
| Метшин<br>Илсур Рәис улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы<br>(килешү буенча) |
| Нигъмәтуллина<br>Гөлшат Рәдиф кызы | Татарстан Республикасы Министр-лар Кабинеты Аппаратының мәдәният һәм Татарстан Республи-касы халыклары телләрен үстерү бүлеге башлыгы |
| Ратникова<br>Римма Атлас кызы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татар-стан Республикасы Журналистлар берлеге идарәсе рәисе (килешү буенча) |
| Садриев<br>Илдар Зөфәр улы | Татарстан Республикасы Министр-лар Кабинеты Аппаратының сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаш-тыру мәсьәләләре бүлеге башлыгы урынбасары |
| Сибагатуллин<br>Айрат Миңнемулла улы | Татарстан Республикасы мәдәният министры |
| Сөнгатуллина<br>Зилә Даян кызы | «Н.Г. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе (акаде-миясе)» федераль дәүләт бюджет югары һөнәри белем бирү мәгариф учреждениесе профессоры, «Йол-дызлык-Созвездие» фестивале жюрие рәисе, Татарстан Респуб-ликасы Иҗтимагый палатасы әгъзасы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Тәхаутдинов<br>Шәфәгать Фәхраз улы | В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Терентьев<br>Александр Михайлович | Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре идарәсе башлыгы |
| Туманов<br>Дмитрий Александрович | «Йолдызлык-Созвездие» иҗади сәләтле балаларга һәм яшьләргә булышлык республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры |
| Хашимова<br>Нурия Миңнәхмәт кызы | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәдәниятне үстерүгә булышлык фонды башкарма директоры |
| Хохорин<br>Артем Валерьевич | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министры (килешү буенча) |
| Шәйхразиев<br>Васил Габтелгаяз улы | «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Шәйхетдинов<br>Роман Александрович | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгълүмат һәм элемтә министры |
| Шакиров<br>Минсәгыйть Закир улы | Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы рәисе (килешү буенча) |

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 1201. Татарстан Республикасының Мөслим районы Тойгелде авылы территориясендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында

Терлекләрнең котыру авырулы булуы ачыклану һәм аның Татарстан Республикасы торак пунктларында таралу куркынычы белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының $3^1$, 17 статьялары нигезендә **карар бирәм**:

1. Терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертергә:

а) Татарстан Республикасының Мөслим районы Тойгелде авылы территориясендә;

б) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә:

Биектау районының Бөреле җәнлек совхозы поселогындагы Уңышлы урамы;

Сарман районының Әлмәт авылындагы Ленин урамы.

2. Әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә карантин гамәле дәвам иткән вакытта түбәндәгеләр тыела:

йорт хайваннарын сату, аларны әлеге территориядән читкә чыгару;

котыру авырулы яисә авыру дигән шик тудыра торган хайваннарны ит өчен суюю;

котыру авырулы терлекләрнең сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә пастеризацияләнмәгән сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә дезинфекцияләнмәгән йонын, тиресен әлеге территориядән чыгару.

3. Карантин, зарури чаралар күрү шарты үтәлгәндә, терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагы көненнән ике ай вакыт узгач бетерелергә тиеш, дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә әлеге Указның 1 пунктында

күрсәтелгән территорияләрдә терлекләрнең котыру белән чирләвен бетерү буенча чаралар планнарын эшләргә һәм расларга, шулай ук аларның гамәлгә ашырылуын тәэмин итәргә.

5. Әлеге Указның үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 20 август
№ ПУ-683

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1202. Татарстан Республикасының Теләче районы Лесной поселогы территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга иминлексезлеге сәбәпле урнаштырылган карантинны бетерү турында

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасының Теләче районы Лесной поселогы территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Теләче районы Лесной поселогы территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2012 елның 11 июнендәге ПУ-461 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 20 август
№ ПУ-684

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 1203. Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында

Терлекләрнең котыру авырулы булуы ачыклану һәм аның Татарстан Республикасы торак пунктларында таралу куркынычы белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының $3^1$, 17 статьялары нигезендә **карар бирәм**:

1. Терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертергә:

а) Татарстан Республикасының түбәндәге торак пунктлары территорияләрендә:

Аксубай районының Такталы авылы;

Балтач районының Иске Көшкәт авылы;

Балык Бистәсе районының Олы Кульга авылы;

б) Кама Тамагы районының Тәмте авылындагы Татарстан урамы территориясендә.

2. Әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә карантин гамәле дәвам иткән вакытта түбәндәгеләр тыела:

йорт хайваннарын сату, аларны әлеге территориядән читкә чыгару;

котыру авырулы яисә авыру дигән шик тудыра торган хайваннарны ит өчен сую;

котыру авырулы терлекләрнең сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә пастеризацияләнмәгән сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә дезинфекцияләнмәгән йонын, тиресен әлеге территориядән чыгару.

3. Карантин, зарури чаралар күрү шарты үтәлгәндә, терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагы көненнән ике ай вакыт узгач бетерелергә тиеш, дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә әлеге Указның 1 пунктында

күрсәтелгән территорияләрдә терлекләрнең котыру белән чирләвен бетерү буенча чаралар планнарын эшләргә һәм расларга, шулай ук аларның гамәлгә ашырылуын тәэмин итәргә.

5. Әлеге Указның үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 20 август
№ ПУ-685

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1204. «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале белән бүләкләү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасының «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы | Габбасов Фәрит Гариф улын |

«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 21 август
№ ПУ-686

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1205. «Татарстан Республикасының Атказанган энергетигы» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм Татарстан Республикасының энергетика тармагын үстерүдәге казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| «Татэнергосбыт» ачык акционер җәмгыяте филиалы – Алабуга бүлекчәсенең участок башлыгы – Мамадыш клиентларга хезмәт күрсәтү офисы җитәкчесе | Телешов Иван Сергеевичка |

«Татарстан Республикасының Атказанган энергетигы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 22 август
№ ПУ-687

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1206. «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасында һәм Россия Федерациясендә милләтара һәм конфессияара татулыкны саклауга һәм үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| Россия мөфтиләре Шурасы Рәисе, Россиянең Европа өлеше мөселманнары Диния нәзарәте Рәисе | Мөфти шәех Равил Гайнетдинны (Гайнетдинов Равил Исмәгыйль улын) |

«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 23 август
№ ПУ-688

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 1207. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының гомуми санын раслау турында» Указына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасының Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсе эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының гомуми санын раслау турында» 2008 елның 23 июнендәге ПУ-300 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 5 мартындагы ПУ-124 номерлы, 2009 елның 13 июнендәге ПУ-328 номерлы, 2009 елның 13 ноябрендәге ПУ-606 номерлы, 2009 елның 17 ноябрендәге ПУ-611 номерлы, 2010 елның 22 мартындагы ПУ-158 номерлы, 2010 елның 21 апрелендәге ПУ-253 номерлы, 2010 елның 10 июнендәге ПУ-378 номерлы, 2010 елның 3 августындагы ПУ-512 номерлы, 2010 елның 11 октябрендәге ПУ-681 номерлы, 2010 елның 1 ноябрендәге ПУ-712 номерлы, 2010 елның 23 декабрендәге ПУ-855 номерлы, 2011 елның 15 гыйнварындагы ПУ-7 номерлы, 2011 елның 31 гыйнварындагы ПУ-33 номерлы, 2011 елның 3 февралендәге ПУ-42 номерлы, 2011 елның 23 мартындагы ПУ-143 номерлы, 2011 елның 11 апрелендәге ПУ-194 номерлы, 2011 елның 29 июлендәге ПУ-459 номерлы, 2011 елның 19 августындагы ПУ-508 номерлы, 2011 елның 5 сентябрендәге ПУ-543 номерлы, 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-620 номерлы, 2011 елның 13 октябрендәге ПУ-646 номерлы, 2011 елның 25 октябрендәге ПУ-676 номерлы, 2011 елның 25 октябрендәге ПУ-677 номерлы, 2011 елның 25 ноябрендәге ПУ-748 номерлы, 2011 елның 30 ноябрендәге ПУ-774 номерлы, 2012 елның 18 гыйнварындагы ПУ-23, 2012 елның 10 мартындагы ПУ-190 номерлы һәм 2012 елның 13 апрелендәге ПУ-257 номерлы, 2012 елның 11 июнендәге ПУ-460 номерлы, 2012 елның 23 июнендәге ПУ-495 номерлы, 2012 елның 27 июлендәге ПУ-622 номерлы, 2012 елның 30 июлендәге ПУ-624 номерлы, 2012 елның 13 августындагы ПУ-649 номерлы һәм 2012 елның 20 августындагы ПУ-680 номер-

лы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) 1 нче кушымтага, 36 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

| | | |
|---|---|---|
| «36 | Татарстан Республикасының Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсе, | 38 |
| | шул исәптән: федераль бюджет акчалары исәбенә финанслanучы вазыйфалар | 20 |
| | Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбенә финансланучы вазыйфалар | 18». |

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә;

үзенең элек бастырып чыгарылган хокукый актларын әлеге Указга туры китерергә;

әлеге Указны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 23 август
№ ПУ-689

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1208. «Татарстан Республикасының Атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык намуслы хезмәте һәм мәгариф өлкәсендәге казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ачык акционер җәмгыятенең «Ямашнефть» нефть-газ чыгару идарәсе прогимназиясе директоры | Калягина Ольга Анатольевнага |

«Татарстан Республикасының Атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 23 август
№ ПУ-690

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1209. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, Татарстан Республикасының нефть сәнәгатен үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ачык акционер җәмгыяте «Елховнефть» нефть-газ чыгару идарәсенең 2 номерлы нефть һәм газ чыгару цехы нефть һәм газ чыгару операторы | Хәсәншин Илдус Гаделша улын |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 23 август
№ ПУ-691

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1210. «Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, финанс-икътисади эшчәнлегендәге казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ачык акционер җәмгыятенең Катлам басымын саклау өчен технологик сыекча әзерләү идарәсе баш бухгалтеры | Ровенская Галимә Асхабутдин кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 23 август
№ ПУ-692

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1211. «Татарстан Республикасының Атказанган нефтьчесе» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, Татарстан Республикасының нефть тармагын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ачык акционер җәмгыяте «Җәлилнефть» нефть-газ чыгару идарәсенең скважиналарны җир астында төзекләндерү цехы скважиналарны җир астында төзекләндерү мастеры | Гобәйдуллин Илшат Тәхаутдин улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган нефтьчесе» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 23 август
№ ПУ-693

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1212. «Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, финанс-икътисади эшчәнлегендәге казанышлары өчен

«Волгопродмонтаж» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш бухгалтеры, Түбән Кама шәһәре — Йосыпова Сәрия Габдрахман кызына

«Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 23 август
№ ПУ-694

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1213. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, Татарстан Республикасының нефть сәнәгатен үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

«Татнефть-Энергосервис» идарә компаниясе җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры — Әфләтунов Радик Әбүзәр улын

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 24 август
№ ПУ-695

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1214. Әлмәт шәһәре төзелүнең 60 еллыгын һәм Татарстан Республикасында нефть ятмаларын эшкәртә башлауның 70 еллыгын бәйрәм итү турында

Татарстан Республикасының икътисадый һәм социаль үсешендә нефть тармагының һәм Әлмәт шәһәренең зур ролен билгеләп, **карар бирәм**:

1. 2013 елның сентябрендә, Нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәрләре көненә туры китереп, Әлмәт шәһәре төзелүнең

60 еллыгын һәм Татарстан Республикасында нефть ятмаларын эшкәртә башлауның 70 еллыгын бәйрәм итәргә.

2. Әлмәт шәһәре төзелүнең 60 еллыгын һәм Татарстан Республикасында нефть ятмаларын эшкәртә башлауның 70 еллыгын бәйрәм итүне әзерләү һәм аны үткәрү буенча оештыру комитеты төзергә һәм аның составын расларга (кушымта итеп бирелә).

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына өч ай эчендә, аларны үткәрү вакытларын, җаваплы башкаручыларны, финанслау күләмнәрен һәм чыганакларын күрсәтеп, Әлмәт шәһәре төзелүнең 60 еллыгын һәм Татарстан Республикасында нефть ятмаларын эшкәртә башлауның 70 еллыгын бәйрәм итүне әзерләү һәм аны уздыру буенча төп чаралар планын эшләргә һәм расларга, шулай ук аны гамәлгә ашыруны контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына, «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» ачык акционер җәмгыятенә, республика һәм җирле массакүләм мәгълүмат чараларына Әлмәт шәһәре төзелүнең 60 еллыгын һәм Татарстан Республикасында нефть ятмаларын эшкәртә башлауның 70 еллыгын бәйрәм итүне киң яктыртуны тәэмин итәргә.

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 ел, 27 август
№ ПУ-696

Татарстан Республикасы
Президентының
2012 елның «27» августындагы
ПУ-696 номерлы Указы
белән расланды

**Әлмәт шәһәре төзелүенең 60 еллыгын һәм Татарстан Республикасында нефть ятмаларын эшкәртә башлауның 70 еллыгын бәйрәм итүне әзерләү һәм аны үткәрү буенча оештыру комитеты составы**

| | |
|---|---|
| Миңнеханов<br>Рөстәм Нургали улы | Татарстан Республикасы Президенты, оештыру комитеты рәисе |
| Халиков<br>Илдар Шәфкать улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры, Совет рәисе |
| Мөхәммәтшин<br>Фәрид Хәйрулла улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, оештыру комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Тәхаутдинов<br>Шәфәгать Фәхраз улы | В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры, оештыру комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Әминов<br>Илшат Юныс улы | «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» ачык акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Баһманов<br>Хәмзә Әзәл улы | Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары |
| Борһанов<br>Рафис Тимерхан улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министры |
| Гайзатуллин<br>Радик Рәүф улы | Татарстан Республикасы финанс министры |
| Гафаров<br>Шамил Хәмит улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе |

| | |
|---|---|
| Гыйльметдинов<br>Альберт Харис улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |
| Зарипов<br>Равил Хаммат улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры |
| Мазһаров<br>Әхмәт Мазһар улы | Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты |
| Мөхәммәдиев<br>Рөстәм Нәбиулла улы | В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ачык акционер җәмгыяте генераль директорының кадрлар һәм социаль үсеш буенча урынбасары (килешү буенча) |
| Сабиров<br>Ринат Касыйм улы | Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе |
| Салихов<br>Мәҗит Хаҗип улы | «Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Сафин<br>Ленар Ринат улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры |
| Сибагатуллин<br>Айрат Миңнемулла улы | Татарстан Республикасы мәдәният министры |
| Тимергалиева<br>Илсөя Нәбиулла кызы | Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының дәүләт бүләкләре бүлеге мөдире |
| Фәйзуллин<br>Ирек Әнвәр улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министры |
| Фәррахов<br>Айрат Зәки улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры |
| Хохорин<br>Артем Валерьевич | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Шәйхетдинов<br>Роман Александрович | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгълүмат һәм элемтә министры |
| Шакиров<br>Минсәгыйть Закир улы | Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы рәисе (килешү буенча) |

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 1215. Татарстан Республикасының Түбән Кама шәһәренең Студентлар урамы территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга иминлексезлеге сәбәпле урнаштырылган карантинны бетерү турында

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының 3[1] статьясы нигезендә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасының Түбән Кама шәһәренең Студентлар урамы территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Түбән Кама шәһәренең Студентлар урамы территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2012 елның 14 июнендәге ПУ-468 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

